СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
«КАРКАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КЕРКӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

10 август 2021 ел

№19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 4 декабрендәге 25а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр тезелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 468-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 4 декабрендәге 25а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

11 статьяда:

5 өлештә «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн»сүзләренә алмаштырырга;

6 өлештә «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

14 статьяның 4 өлешендә «Комиссия» сүзеннән соң «мондый фикер алышулар яисә тыңлаулар тәмамланганнан соң унбиш эш көне эчендә»сүзләре белн тулыландырырга.

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Керкәле авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Г.Х.Шириязданова